# Рәхмәт барысы өчен дә, Мининур Хәмәтовна!

2025 елның 12 сентябрендә авылыбызның Почетлы гражданины, Татарстаннын атказанган врачы, Яр Чаллы шәһәренең «Алтын йөрәкле кеше» бүләге кавалеры, БСМПда озак еллар хирург булып эшләгән Мининур Хәмәт кызы Гайфетдинова Яр Чаллыда үзенең хезмәт юлын тәмамлап улы Айрат янына Казан шәһәренә күчеп китте. БСМП коллективы, җитәкчеләре аны бик җылы итеп озаттылар.

Мининур Хәмәт кызы медицинада 1977 елдан бирле хезмәт куя. Казан медицина училищесын тәмамлагач ул Казанда ук медсестра булып эшли башлый. 1980 елда Казан медицина институтына укырга керә. Ул анда хатын-кызлар өчен хас булмаган «хирург» һөнәре алып чыга һәм туган якларга якын булган Яр Чаллы шәһәренә эшкә кайта. Авылыбызда, тирә-як авылларда аңа ярдәм сорап мөрәҗәгать итмәгән кешеләр бар микән? Барысына да ярдәм итәргә вакыт та, йөрәк җылысы да тапты Мининур Хәмәтовна. Көндез дә, төнлә дә операция өстәле артында торып күпме кешеләргә тормыш бүләк итте ул! Шулай итеп 50 елга якын вакыт үтеп тә китте!

Мининур Хәмәтовна! Әйтеп бетергесез күп рәхмәт Сезгә барлык изге гамәлләрегез өчен! Сезгә ныклы сәламәтлек, балаларыгыз, оныкларыгыз белән бергә бәхетле озын гомер итүегезне телибез! Без Сезне гел сагынырбыз. Бәзәкәне дә онытмагыз: сабантуйларга көтеп калабыз!